ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                 КАРАР
_____________          01.02.2024   ПР-20                                № _________

**«Капиталь төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесен бетерү турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясының 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре эшчәнлеген оптимальләштерү максатларында, Актаныш муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Түбәндәге адрес: 423740, ТР, Актаныш районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 17 йорт, оф 19 буенча урнашкан «Капиталь төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесен (алга таба – Предприятие) бетерергә.

2. Бетерү чараларын үткәрү өчен түбәндәге составта предприятиенең бетерү комиссиясен төзергә:

| | |
|---|---|
| Хузин Рамил Радист улы | - предприятияне бетерү комиссиясе рәисе; |
| Зәйнетдинов Булат Рифат улы | - предприятие директоры, бетерү комиссиясе әгъзасы; |
| Шаехова Ильвира Марс кызы | - предприятиене бетерү комиссиясе әгъзасы. |

3. Бетерү комиссиясенә:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) белән Предприятие эшләре белән идарә итүгә бетерү процессында (алга таба - Килешү) шартнамә төзергә һәм әлеге законнарда каралган предприятиене бетерү буенча барлык кирәкле гамәлләрне башкарырга;
- предприятиене 30.09.2024 елга кадәр бетерергә;

4. Бетерү комиссиясе рәисенә:

- Предприятиенең барлык хезмәткәрләренә алда торган азат итү турында хәбәр итәргә, хезмәткәрләргә законнарда каралган гарантияләрне тәэмин итәргә, гамәлдәге законнарда каралган башка бетерү чараларын гамәлгә ашырырга;
- предприятиене бетерү һәм бетерү комиссиясен билгеләү турында предприятие урнашкан урын буенча юридик затларны теркәүне гамәлгә ашыручы оешмага хәбәр иткәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга.

5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының “Капиталь төзелеш идарәсе” муниципаль унитар предприятиесен бетерү турында” 23.01.2024 ел, № ПР-8 карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы И.Ш.Бариевка йөкләргә.

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 621DCE305601C88D15496913AD135909
Владелец: Ильясов Рустем Алмазович
Действителен с 10.04.2023 до 03.07.2024

Җитәкче                                                                 Р.А.Ильясов